# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**12 нче ноябрь 2022 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законыныц 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, махсус хәрби операциягә киткән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- Сәпәй авылында юлларны чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен карны механикалаштырып җыю буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (мәчет, авыл клубы, ФАП һәм балалар бакчасы территориясе), территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту, территорияләрне яшелләндерү чаралары) Сәпәй авылында территорияне санитар чистарту буенча хезмәт күрсәтү ;

- Сәпәй авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү);

- Сәпәй авылында күмелгән урыннарны карап тоту (дератизация, тоташ гербиңид белән химик эшкәртү, агач кисү, куакларны кисү, үлән чабу, чүп-чар җыю, хуҗалык инвентаре, инструментлар һәм җиһазлар алу);

- Сәпәй авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сәпәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

(http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Галиева